# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

## КАРАР

20 ноябрь 2017 ел № 134

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге территориясендә 2017 елның 19 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында»Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә районы территориаль сайлау комиссиясе (ИКМО) 2017 елның 19 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде, аның нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 136 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны — 136, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның 100 % ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен референдумда катнашучыларның 136 е тавыш бирде, Бу тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның 100 % ын тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашучыларның 0 е тавыш бирде, бу 0 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әтнә районы Югары Сәрдә авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган дип, референдум нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. "2018 елда Югары Сәрдә авыл җирлегендә яшәүче 18 яшькә җиткән, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

1) Югары Сәрдә авылында балалар мәйданчыгы сатып алу һәм аны урнаштыру;

2) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- Югары Сәрдә авыллы зираты территориясендәге агач һәм куакларны кисү, чистарту, Югары Сәрдә авыллы зираты коймасы өчен материалар алу.

3) Авыл җирлеге территориясендә җирле әһәмияттәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Югары Сәрдә авылында урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү буенча хезмәтләр өчен түләү дигән мәсьәләләр буенча карарны кабул ителгән дип санарга.

3. Аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны экономияләү очрагында, әлеге акчалар планлаштырылган эшләрне башкару өчен акча җитәрлек булмаган юнәлешләрне финанслауга юнәлтелә.

4. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Этнә таңы» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http/ / atnya. tatarstan. ru. адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әтнә районы Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Әтнә районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе С.Н.Ахмадуллин

Татарстан Республикасы Әтнә районы
территориаль сайлау комиссиясе сәркәтибе А.К.Аскарова